РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423739, д. Качкиново,
ул.Центральная, дом 37/в.
Тел/факс 5-30-38.
e-mail : usin.akt@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур.,37/в нче йорт.
Тел/факс 5-30-38
e-mail : usin.akt@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
25.02.2020 ел

**КАРАР**
№ 3

**Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Советының 17.03.2016 ел, №3 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы , «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында, Усы авыл җирлегенең 17.03.2016ел №3 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның «в» пунктчасында «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә»;

1.2. 13 пунктта «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Усы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Усы авыл җирлеге Советы Рәисе — З.З.Ахмаев